**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БЕССОНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БЕССОНОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 51-2-18, факс 51-2-18

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16 .11. 2021** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоновка авыл җирлегенең Бессоновка торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Бессоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 ст. нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Бессоново авылы, Стахановская урамы, 12 нче йорт адресы буенча урнашкан Бессоново авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 30 ноябрендә 14 сәгать 30 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең Бессоново авыл җирлегендә 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, күп балалы гаиләләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына эшкә чакырылган гражданнардан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (авыл эчендәге юлларны ремонтлау, вак таш, төзелеш комы сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, килешү буенча түләү).;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш түшәмәле чокырлар ремонтлау: сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).;
- Бессоново т. п. урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктырту буенча агымдагы ремонт һәм аларга хезмәт күрсәтү)
- буаны ремонтлау (смета буенча: җир өеме урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) Бессоново т. п. Полевая урамы буенча?»

«КАРШЫ» “РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бессоново авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан

Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ю.А. Врясов**